ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 4 2021 ел, 8 ноябрь

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Мюд поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Мюд поселогы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Мюд поселогы, Үзәк урамы, 35 йорт адресы буенча урнашкан, Мюд авыл мәдәният йорт бинасында билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

   «2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Мюд поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме?:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге; - Мюд поселогы торак пункты чикләрендә вак таш түшәмәле юл полотносы урнаштыру (грунтлау, грейдлау, вак таш түшәү, ком сибү, килешү буенча эшләр өчен түләү). - Мюд поселогы торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) - күпер ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу).

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, агынты суларны чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Мюд поселогында тирән насос сатып алу һәм алыштыру, сууткәргечне ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина